Ф. Г. Казыйханова, В. С. Казыйханов

МАТЕМАТИКА

МАТЕМАТИКА

2

«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ


5+2=7

Ф. Г. Казыйханова, В. С. Казыйханов

МАТЕМАТИКА

Дүртьеллык башлангыч татар мәктәбенең
2 нче сыйныфы өчен дәреслек

*Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
рөхсәте белән басыла*

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2008

УДК 373.167.1 : 51 * 02
ББК 22.1 я71
К16

Рәссамы *Р. А. Сәйфуллина*

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Казыйханова Ф. Г.

К16 Математика : Дүртьеллык башл. татар мәкт. 2 нче с-фы өчен д-лек / Ф. Г. Казыйханова, В. С. Казыйханов.— Казан : Мәгариф, 2008.— 144 б.: рәс. б-н.

ISBN 978-5-7761-1804-3

ISBN 978-5-7761-1804-3

© «Мәгариф» нәшрияты, 2008
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2008

1 100 ЭЧЕНДӘ КУШУ ҺӘМ АЛУ.

1 Бер цифр гына кулланып, барлык икеурынлы саннарны яз. Ничә сан яздың? Цифрлар ничә?

2 1 һәм 2 цифрларын кулланып, икеурынлы сан яз.

3 2 һәм 0 цифрларын кулланып, икеурынлы сан яз.

4 Берурынлы саннарны үсә бару тәртибендә яз. Ничә сан яздың?

5 20 гә кадәр икеурынлы саннарны үсүче рәткә тезеп яз.

6 6 дан 20 гә кадәр икеурынлы саннарны кимүче рәткә тезеп яз.

Цифрлар: 0, 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9.
Саннар — чиксез күп.

7 Саннарны разрядлар таблицасына яз.

4 дистә 6 берәмлек 6 дистә 2 берәмлек
2 дистә 7 берәмлек 5 дистә 3 берәмлек

8 Разрядлар таблицасына язып чиш.

6 дистә 3 берәмлек + 1 дистә 2 берәмлек
9 дистә 6 берәмлек − 2 дистә 3 берәмлек
5 дистә + 3 берәмлек

9 Баганалап язып чиш.

53 + 24 46 + 13 62 + 37
75 − 12 15 + 2 49 + 50

10 Саннарны чагыштыр.

41 * 41 61 * 57 78 * 81
45 * 55 56 * 79 40 * 49

11 Саннарны үсә бару тәртибендә урнаштыр.

21, 19, 32, 46, 31, 20, 52

12 Иң зур санны гына яз.

41, 55, 43, 54, 68, 39, 89, 99

13 x ны тап. Ялгышма!



14 Исеңә төшер!



15 *x* ны тап.



x ны тапканда нинди гамәл кулландың?

16 Исеңдә калдыр!



17 *x* ны тап. Ялгышма!



18 Мисалларны чиш.

34 − 12	33 + 40	92 + 7
44 − 3	4 + 35	80 + 9

19 Телдән исәплә.

2 дистә + 4 дистә   30 + 20
8 дистә − 3 дистә   70 − 40

20 Мәсьәлә төзе һәм чиш.



21 Схемага карап, таблицаны тутыр.



a	1			4			7	9	
b		2	3		5	6			8

22 Беренче баганадагы кебек мисаллар яз.

8 + 1	7 + 1	6 + 2	4 − 3
80 + 10			
800 + 100			

23 Мисалларны чиш.

40 + 10	40 − 10	90 − 80
60 + 30	60 − 30	80 − 70
20 + 50	50 − 20	20 − 10

24 x ны тап. Ялгышма!



25 Сызым буенча тигезләмә яз. x ны тап. Ялгышма!



26 Алу гамәле белән эшләнә торган тигезләмәләрне генә чиш. Ялгышма!

$x - 41 = 23$	$30 + x = 50$	$x - 52 = 47$
$43 - x = 11$	$62 - x = 40$	$x + 9 = 99$
$x + 10 = 30$	$14 + x = 26$	$99 - x = 52$

27 x ны тап.



28 $20 + 10 = 30$ тигезлеген кулланып, өч тигезләмә яз.

29 Таблицаны тутыр.

a	4		5	2		1	1	
b	6	3		8	7	6	9	6
$a+b$		10	10		10			10

30 Билгесез кушылучыны яз.

	1	4
+		
	4	6

	3	4
+		
	7	4

+	4	8
	5	9

31 Кибеттә ике көндә күпме көзге сатылганын ничек исәпләгәнне аңлат.

	3	6
+	4	5
	7	12
	8	2

32 Сумманы тап.

2 нче разрядтан башла

	1	8
+	1	3

1 нче разрядтан башла

	3	7
+	2	6

Ничек уңайлырак?

33 Цифрлар суммасы 10 га тигез яки 10 нан зуррак булган разрядларны тап:

$\begin{array}{r}36\\+\,23\\\hline\end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r}65\\+\,25\\\hline\end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r}65\\+\,16\\\hline\end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r}12\\+\,43\\\hline\end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r}48\\+\,36\\\hline\end{array}$

34 Сумманы язып бетер. 1 санын алдагы разрядның өске өлешенә яз. Ук белән күрсәт.

$\begin{array}{r}{\scriptstyle 1}\;\;\\14\\+\,17\\\hline\end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r}56\\+\,6\\\hline\end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r}23\\+\,8\\\hline\end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r}46\\+\,18\\\hline\end{array}$

35 Җавабы 10 га тигез яки 10 нан зуррак булган мисалларны гына чиш.

$3 + 6$	$3 + 8$	$6 + 5$	$3 + 5$
$3 + 7$	$4 + 5$	$7 + 4$	$8 + 2$

36 □ урынына тиешле саннар яз.

$5 + \square = 6 + \square = 7 + \square = 8 + \square = 10$

37 Мәсьәлә төзе. x ны тап. Ялгышма!







38 Баганалап язып исәплә. Схема кулллан. Фәриданең шәхси китапханәсеннән 27 китап алгач, 64 китап калган. Фәриданең китапханәсендә ничә китап булган?

39 Кайсы разрядта цифрлар суммасы 10 га тигез яки 10 нан зур була? Ук белән күрсәт. Сумманы исәплә.

$\begin{array}{r} 37 \\ +\ 43 \\ \hline \end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r} 53 \\ +\ 14 \\ \hline \end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r} 58 \\ +\ 34 \\ \hline \end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r} 48 \\ +\ 25 \\ \hline \end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r} 51 \\ +\ 29 \\ \hline \end{array}$

40 Баганалап язып исәплә.

46 + 24 $\quad$ 49 + 21 $\quad$ 46 + 26
34 + 56 $\quad$ 82 + 8 $\quad$ 43 + 7

41 Мисалларны чиш.

$\begin{array}{r} 26 \\ +\ 64 \\ \hline \end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r} 27 \\ +\ 46 \\ \hline \end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r} 48 \\ +\ 22 \\ \hline \end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r} 33 \\ +\ 57 \\ \hline \end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r} 46 \\ +\ 28 \\ \hline \end{array}$

42 Беренче кушылучыны яз.

$* + 80 = 90$ $\quad$ $* + 20 = 50$
$* + 6 = 10$ $\quad$ $* + 3 = 10$
$* + 40 = 60$ $\quad$ $* + 0 = 0$

43 Укка карап, саннар аермасын табуны аңлат.

3	10
4	2
− 2	4

5	10
6	3
− 2	8

44 Гамәлне башкар.

5	3
− 2	9

6	2
− 2	4

6	0
− 3	6

45 Киметүчене яз. Аерманы тап.

4	10
5	4
−	

3	10
4	5
−	

5	10
6	0
−	

46 Кимүчене яз. Аерманы тап.

	10
− 2	4

	10
− 4	5

	10
− 4	3

47 Схема кулланып исәплә.

Кибеттә 60 чиләк бар иде. Берничә чиләкне саткач, 21 чиләк калды. Ничә чиләк сатылган?

48 Баганалап язып исәплә.

48 − 29	33 − 17	54 − 37
57 − 8	94 − 46	75 − 36

$$c - a = b$$

кимүче — киметүче — аерма

49 Мисаллар дөрес чишелгәнме? Тикшер. Ялгышлык нәрсәдә?

$$\begin{array}{r} 46 \\ +\,18 \\ \hline 64 \end{array} \qquad \begin{array}{r} 52 \\ +\,9 \\ \hline 61 \end{array} \qquad \begin{array}{r} 27 \\ +\,18 \\ \hline 85 \end{array} \qquad \begin{array}{r} 34 \\ 18 \\ \hline 42 \end{array}$$

50 Беренче баганадагы мисаллар икенчесендәгедән нәрсә белән аерыла?

4 + 3	4 + 6
5 + 4	5 + 7
6 + 2	6 + 8
7 + 2	7 + 4

51 Җавапта берурынлы сан булсын өчен, ? билгесе урынына нинди саннар язарга?

4 + ? =   3 + ? =   ? + 7 =
5 + ? =   6 + ? =   ? + 2 =

52 Җавапта икеурынлы сан булырлык итеп, ? билгесе урынына берурынлы саннар яз.

4 + ? =   6 + ? =   ? + 8 =
5 + ? =   ? + 7 =   ? + 9 =

53 Берурынлы саннарны кушуга мисаллар язуны дәвам ит.

9 + 1	8 + 2	7 + 3	6 + 4
9 + 2	8 + 3	7 + 4	...
9 + 3	8 + 4	...	
...	...		

54 46 + 26 гамәлен кулланып чишелә торган мәсьәлә төзе.

55 Берурынлы саннарны кушуның кайсы ысулы уңайлырак?

Беренче ысул: $9 + 6 = (9 + 2) + 4 = 11 + 4 = 15$
(6 = 2 + 4)

Икенче ысул: $9 + 6 = (9 + 1) + 5 = 10 + 5 = 15$
(6 = 1 + 5)

Җәяләр нәрсәне аңлата?

56 Мисалларны уңайлы юл белән чиш.

$9 + 7$ $6 + 7$ $9 + 8$

$8 + 4$ $8 + 6$ $5 + 9$

57 Берурынлы саннарны кушу таблицасын тутырып бетер.

	1	2	3	4	5	6	7	8	9
1		3							
2			5						
3									
4						10			
5									14
6								14	
7							14		
8						14			
9					14				

58 Таблицадагы суммалардан иң зур һәм иң кечкенә санны тап. Иң зур берурынлы, иң кечкенә икеурынлы санны күрсәт.

59 Ни өчен таблицадагы икеурынлы саннарның беренче цифры бертөрле?

60 x тан башлап, мәсьәлә төзе һәм чиш.



61 Баганалап язып исәплә. Икенче баганадагы мисаллар беренчесеннән нәрсә белән аерыла?

38 − 15	34 − 18
49 − 8	42 − 25
57 − 34	45 − 16

62 Кайсы юл уңайлырак?

$12 - 8 = (12 - 3) - 5 = 9 - 5 = 4$

3 5

$12 - 8 = (12 - 2) - 6 = 10 - 6 = 4$

2 6

Җәяләр нәрсәне аңлата?

63 Киметүчене уңайлы өлешләргә бүл. Ялгышма!

16 − 9	18 − 8	19 − 9
15 − 8	14 − 6	17 − 9

64 Мисалларны уңайлы ысул белән чиш.

13 − 5	12 − 5	11 − 2
14 − 7	15 − 8	12 − 4
15 − 8	16 − 7	18 − 9

65 Мисалларны баганалап язып чиш.

94 − 46	40 − 32	92 − 47
43 − 18	65 − 5	83 − 36

66 Сызым буенча x тан башлап мәсьәлә төзе һәм чиш.



67 Мисалларны чишмичә генә, җавапта ничә урынлы сан буласын әйт.

$\begin{array}{r} 72 \\ +\ 19 \\ \hline \end{array}$ $\begin{array}{r} 48 \\ -\ 39 \\ \hline \end{array}$ $\begin{array}{r} 56 \\ -\ 47 \\ \hline \end{array}$ $\begin{array}{r} 19 \\ +\ 71 \\ \hline \end{array}$

68 Алу гамәле белән чишелә торган тигезләмәләрне генә эшлә.

$36 + x = 41$ $x - 43 = 28$
$54 - x = 27$ $x + 59 = 88$

69 Цифрлары суммасы иң кечкенә ике-урынлы санга тигез булган иң кечкенә икеурынлы санны яз.

70 Цифрлары суммасы 8 гә тигез булган икеурынлы саннарны яз. Ничә сан яздың?

71 Дистәләр саны берәмлекләр саныннан 2 гә зуррак булган икеурынлы санны яз. Аның цифрлар суммасы 8 гә тигез булсын.

72 Разряд берәмлеген вакларга кирәк булуын күрсәткән уклар куй.

24 – 7	52 – 31	84 – 70
50 – 23	42 – 6	23 – 15

73 Ак һәм кызыл төстәге 11 чәчәктән бәйләм ясаганнар. Бәйләмдә ничә ак, ничә кызыл чәчәк бар?

74 73 нче күнегүдәге мәсьәләнең соравына ни өчен төгәл җавап бирә алмадың? Бәйләмдә ак чәчәкләр 2 гә күбрәк булган дигән шарт өстәлсә, мәсьәләнең җавабын табып буламы?

75 Ак чәчәкләр саны 3 кә артык дигән шартны өстәп, 73 нче мәсьәләне чиш.

76 Бирелгән схеманы кулланып, мәсьәлә төзе.



77 Сызымны кулланып, мәсьәлә төзе һәм чиш.



78 Тигезләмә буенча мәсьәлә төзе.

$$x - 20 = 45$$

79 Мисалларны чиш.

$\begin{array}{r} 67 \\ +\,18 \\ \hline \end{array}$ $\begin{array}{r} 48 \\ +\,26 \\ \hline \end{array}$ $\begin{array}{r} 59 \\ +\,12 \\ \hline \end{array}$ $\begin{array}{r} 66 \\ +\,25 \\ \hline \end{array}$

80 Җавапта икеурынлы сан булган мисалларны аерып яз.

$8 + 1$	$3 + 9$	$5 + 2$	$8 + 9$
$8 + 4$	$2 + 1$	$4 + 7$	$5 + 8$
$3 + 5$	$6 + 8$	$3 + 4$	$4 + 6$

81 Мисалларны чишүнең иң уңайлы ысулы кайсы? Ни өчен?

$9 + 6$	$8 + 7$	$6 + 5$
$(9 + 5) + 1$	$(8 + 4) + 3$	$(6 + 3) + 2$
$(9 + 3) + 3$	$(8 + 2) + 5$	$(6 + 4) + 1$
$(9 + 2) + 4$	$(8 + 5) + 2$	$(6 + 2) + 3$
$(9 + 1) + 5$	$(8 + 3) + 4$	$(6 + 1) + 4$

82 Уңайлы ысул белән исәплә.

$7 + 7 = (7 + 3) + 4 = 10 + 4 = 14$

$9 + 5$	$7 + 8$	$9 + 4$	$6 + 7$
$8 + 6$	$8 + 5$	$8 + 8$	$9 + 9$

83 11, 9 һәм 2 саннарын сызымда дугалар белән күрсәт.

84 ? билгесе урынына тиешле саннарны яз.

? + (3 + 4) = 14 ? + (5 + 3) = 13

? + (6 + 3) = 13 ? + (8 + 1) = 11

85 Сумманы уңайлы юл белән исәпләрлек итеп, кушылучыны өлешләргә бүл.

7 + 5 (5 → * *) 6 + 8 (6 → * *) 9 + 4 (4 → * *)

8 + 8 (8 → * *) 5 + 8 (5 → * *) 9 + 6 (6 → * *)

86 Уңайлы ысул белән исәплә.

$8 + 7$	$7 + 6$	$5 + 7$	$9 + 7$

87 a, b, c зурлыкларын сызымда дуга белән күрсәт: $a < b$ (c га).

88 Сызымдагы ? билгесе урынына хәрефләр яз. $a > b$ (m га).

89 Дугалар янына саннар яз.

90 Мисалларны чиш.

$$\begin{array}{r} 48 \\ +\ 38 \\ \hline \end{array} \qquad \begin{array}{r} 25 \\ +\ 58 \\ \hline \end{array} \qquad \begin{array}{r} 49 \\ +\ 42 \\ \hline \end{array} \qquad \begin{array}{r} 34 \\ +\ 28 \\ \hline \end{array}$$

91 Парлап язылган мисалларны чишү. Алар бер-берсеннән нәрсә белән аерыла? Кайсыларын чишү җиңелрәк?

10 + 1	10 + 3	10 + 5	10 + 8
9 + 2	9 + 4	9 + 6	9 + 9

92 Ничек эшләү уңайлырак?

$9 + 3 = (9 + 2) + 1$ $\qquad$ $9 + 3 = (9 + 1) + 2$

$9 + 7 = (9 + 5) + 2$ $\qquad$ $9 + 7 = (9 + 1) + 6$

93 Таблицаны тутыр.

a	9	10	11	12	13	14	15	16	17	18
$a-9$			2		4		6			

94 Уңайлы ысул белән исәпләрлек итеп, 9 санын өлешләргә бүл.

8 + 9	7 + 9	6 + 9
8 + (2 + 7)	7 + (* + *)	6 + (* + *)

5 + 9	9 + 9	4 + 9
5 + (* + *)	9 + (* + *)	4 + (* + *)

95 9 санына берурынлы саннарны кушу таблицасын ятла.

a	1	2	3	4	5	6	7	8	9
$9+a$	10	11	12	13	14	15	16	17	18

96 Таблицаны файдаланып чиш.

49 + 46   39 + 15   59 + 17
25 + 49   29 + 28   69 + 24

97 Самавырга 15 чынаяк су сыя. d чынаяк эчкәч, самаварда күпме (k) су кала? k ны төрле юллар белән сызымда күрсәт.





98 Югарыдагы мәсьәләдә d белән k нинди саннарга тигез булырга мөмкин?

99 Уңайлы ысул белән исәплә.

45 − 7 − 5   13 − 3 − 5   84 − 8 − 4
38 − 3 − 8   58 − 8 − 3   76 − 6 − 4

100 9 га берурынлы саннарны кушу таблицасын ятладыңмы? Хәтердән яз.

m	9	8	7	6	5	3	2	1	4
$9+m$				15					13

101 Дөреслеген тикшер.

9 + 5 = 14   9 + 4 = 13   7 + 6 = 15
9 + 7 = 16   9 + 6 = 14   9 + 8 = 17

102 Баганалап язып исәплә.

49 + 25   81 + 9   9 + 22   8 + 35
23 + 47   96 + 3   36 + 9   11 + 79

103 Мисалларның җавабын таблицага язып бар.

9 + 1   9 + 5   9 + 2   9 + 6
9 + 3   9 + 4   9 + 7   9 + 8

m	1	2	3	4	5	6	7	8	9
$9 + m$									18

104 Таблица кулланып исәплә.

1 + 9   5 + 9   2 + 9   6 + 9
3 + 9   4 + 9   9 + 7   8 + 9

105 Сызымда күрсәт. Бер вазада a алма бар, икенчесендә 9 га күбрәк.

106 Схемага яз. Бер бүлмәдә b өстәл бар, икенчесендә 9 га кимрәк.



107 Уңайлы ысул белән исәплә.

49 – 1 – 9   57 – 7 – 5   33 – 3 – 9
68 – 8 – 2   49 – 2 – 9   42 – 9 – 2

108 Баганалап язып исәплә.

91 + 8   32 + 19   23 + 9
46 + 19   45 + 9   9 + 66

109 Сызымдагы ук очына нинди сан туры килә?



110 x ны тап.

$x + 9 = a$ $\qquad$ $9 + x = 17$ $\qquad$ $x + 9 = 15$

111 Йолдызчыклар урынына тиешле цифрлар яз.

$$\begin{array}{r|l} 5 & 3 \\ +\,1 & * \\ \hline * & 9 \end{array} \qquad \begin{array}{r|l} 4 & 9 \\ +\,3 & * \\ \hline * & 8 \end{array} \qquad \begin{array}{r|l} 3 & * \\ +\,4 & 9 \\ \hline * & 2 \end{array}$$

112 Схема ярдәмендә чиш.
Бер төргәктә берничә метр тасма бар иде. 9 м ын кисеп алгач, төргәктә 18 м тасма калды. Төргәктә ничә метр тасма булган?

113 Тигезләмә төзеп чиш.
Савытта 40 л сөт бар иде. Беразын бушаткач, 29 л сөт калды. Ничә литр сөтне бушатканнар?

114 Сызым сызып чиш.
Бүлмәдә 39 урындык һәм a өстәл бар. Урындыклар өстәлләргә караганда 20 гә күбрәк. Бүлмәдә ничә өстәл бар?

115 ? билгесе урынында нинди сан?

14 = 9 + ?   12 = 9 + ?   13 = 9 + ?
17 = 9 + ?   16 = 9 + ?   15 = 9 + ?

116 Мисалларны чиш.

14 – 9   12 – 9   13 – 9
17 – 9   16 – 9   15 – 9

117 Баганалап язып исәплә.

54 – 29   45 – 29   45 – 19
76 – 19   96 – 29   35 – 9

118 Сызым сызып чиш.
Бер кәрзиндә 59, икенчесендә c алма бар. Икенче кәрзиндә беренчесендәгедән 12 алмага күбрәк. Икенче кәрзиндә ничә алма бар?

119 a, b һәм c ны схемага яз. $a > b$ (аерма c).



120 Тигезләмә төзеп чиш.
Әтисенә 32, кызына x яшь. Әтисе кызыннан 29 яшькә олырак. Кызына ничә яшь?

121 Беренче баганадагы мисаллар икенче баганадагы мисаллардан нәрсә белән аерыла?

18 − 9	18 − 6
17 − 9	17 − 4
15 − 8	15 − 3
13 − 4	13 − 2

122 Уңайлы исәпләү юлын күрсәт.

18 − 9	17 − 9	15 − 8
18 − 5 − 4	17 − 3 − 6	15 − 3 − 5
18 − 4 − 2	17 − 7 −2	15 − 5 − 3
18 − 8 − 1	17 − 1 − 8	15 − 1 − 7

123 Киметүчене уңайлы өлешләргә бүл.

16 − 8 (6, 2)	15 − 7	14 − 6
13 − 4	18 − 9	16 − 9

124 $m < k$ (аерма d). Сызым яса. d зурлыгын тап.

125 Бер бакчадан a капчык, икенчесеннән b капчык кыяр җыеп алганнар. Икенче бакчадан беренчесенә караганда c капчык кыяр артык алынган. Сызымнарга карап, өч мәсьәлә төзеп чиш.



$a = 24$
$c = 19$
$b = ?$



$b = 59$
$c = 17$
$a = ?$



$a = 22$
$b = 49$
$c = ?$



126 Баганалап язып исәплә.

49 + 46	48 + 21	53 + 9
52 + 23	49 + 29	40 + 9

127 Киметүчене уңайлы өлешләргә бүлеп, мисалларны чиш.

$18 - 9 = 18 - 8 - 1 = 10 - 1 = 9$
(9 = 8 + 1: 8, 1)

17 – 9	14 – 9	15 – 9
13 – 9	16 – 9	12 – 9

128 Парлап бирелгән мисалларны чагыштыр. Икенче юлда бирелгән мисалларны ничек чишеп була?

18 – 10   16 – 10   14 – 10
18 – 9   16 – 9   14 – 9

129 Схемада * урынына тиешле саннар яз.



130 Таблицаны ятла!

$9+a$	18	17	16	15	14	13	12	11	10
a	9	8	7	6	5	4	3	2	1

131 Сызым сызып чиш.

Мәктәпнең бер бүлмәсендә 42 урындык бар, икенчесендә 12 гә кимрәк. Икенче бүлмәдә ничә урындык бар?

Җавапны табу өчен, ничә гамәл кулландың?

132 Мәктәпнең бер бүлмәсендә 42 урындык бар, икенчесендә 12 гә кимрәк. Ике бүлмәдә ничә урындык бар?



Мәсьәләне ничә гамәл ярдәмендә чиштең?

133 Мисалларны баганалап язып чиш.

$56 + 42$ $67 - 18$ $78 - 19$
$39 + 53$ $48 - 29$ $93 - 28$

134 Таблицаны тутыр.

a	3	5	6			2	4
$7 + a$				15	16		

135 Тигезләмәләрне чиш.

$x + 53 = 82$ $x - 36 = 47$
$44 + x = 61$ $69 - x = 18$

136 Мәсьәләне сызым сызып чиш.
Бер тартмада 50 алма бар, ә икенчесендә 36 алмага күбрәк. Ике тартмада ничә алма бар?

137 88 лимонның 29 ыннан кайнатма ясадылар. Ничә лимон калды? Мәсьәләне тигезләмә төзеп чиш.

138 Схема буенча мәсьәлә төзе.



2 ӨЧУРЫНЛЫ САННАР.

139 Мәсьәләне схема сызып чиш.
Ләйләнең 60 сум акчасы булган. Әтисе тагын 40 сум биргән. Кызның барысы ничә сум акчасы булды?

140 Ләйләнең 100 сум акчасы бар. Әгәр тагын 100 сум бирсәләр, аның күпме акчасы булыр?

141 Ләйләнең 200 сум акчасы бар. Әгәр аңа тагын 100 (200, 300, 400, 500, 600, 700) сум бирсәләр, аның күпме акчасы булыр?

142 100, 200, 400, 900 саннарында ничә дистә бар?

143 Разрядлар таблицасына яз.
9 йөз 6 дистә 5 берәмлек, 6 йөз 4 берәмлек, 7 йөз 4 дистә.

144 Иң кечкенә һәм иң зур өчурынлы саннарны яз.

145 500 нең 100 ен дистәләргә ваклап, таблицага яз.

йөзләр	дистәләр	берәмлекләр
5	0	0

146 500 санының 1 дистәсен ваклап, югарыдагы таблицага яз.

147 Кайсы разряд берәмлеге вакланганын ук белән күрсәт. Җавапларны тап.

$$\begin{array}{r} 642 \\ -\,328 \\ \hline \end{array} \qquad \begin{array}{r} 546 \\ -\,263 \\ \hline \end{array} \qquad \begin{array}{r} 841 \\ -\,453 \\ \hline \end{array} \qquad \begin{array}{r} 600 \\ -\,142 \\ \hline \end{array}$$

148 * урынына тиешле цифрларны яз.

$$\begin{array}{r} 464 \\ +\,1{*}3 \\ \hline {*}3{*} \end{array} \qquad \begin{array}{r} 6{*}3 \\ -\,44{*} \\ \hline {*}62 \end{array} \qquad \begin{array}{r} {*}3{*} \\ -\,4{*}5 \\ \hline 227 \end{array}$$

149 Сызым буенча каз бәбкәләре һәм чебиләр турында ике мәсьәлә төзе. Берсендә «күбрәк», икенчесендә «азрак» сүзен куллан.



150 Мисалларны чиш.

$\begin{array}{r} 149 \\ +\quad 56 \\ \hline \end{array}$ $\qquad$ $\begin{array}{r} 256 \\ -\quad 96 \\ \hline \end{array}$ $\qquad$ $\begin{array}{r} 305 \\ +\ 685 \\ \hline \end{array}$

151 Икенче кушылучыны ике өлешкә бүл. Беренче өлеше 2 гә тигез булсын.

8 + 6 $\qquad$ 8 + 5 $\qquad$ 8 + 7 $\qquad$ 8 + 4

2 4

152 Таблицаны тутыр.

a	7	6	8	5	3	4	2
$8 + a$				13			

153 Югарыдагы таблицаны файдаланып, мисалларны чиш.

16 − 8 $\qquad$ 15 − 8 $\qquad$ 12 − 8 $\qquad$ 17 − 8
14 − 8 $\qquad$ 13 − 8 $\qquad$ 11 − 8 $\qquad$ 15 − 8

154 Мәсьәләгә ике төрле сызым бирелгән. Сызымнарга саннар яз.

а) 

ә)

Рәшит 92 көнлек җәйге ялының 27 көнен авылда, калган көннәрен шәһәрдә уздырды. Ул җәйге ялының ничә көнен шәһәрдә үткәргән? Мәсьәләне тигезләмә төзеп чиш.

155 Схемаларга карап, тигезләмәләр төзе һәм чиш.



156 Мисалларны чиш.

$$\begin{array}{r} 248 \\ -\ 138 \\ \hline \end{array} \qquad \begin{array}{r} 546 \\ -\ 283 \\ \hline \end{array} \qquad \begin{array}{r} 841 \\ -\ 458 \\ \hline \end{array}$$

157 Мисалларны чиш.

$7 + 7$ (3 4) $\quad 7 + 9$ (3 6) $\quad 7 + 4 \quad 7 + 3$

$7 + 5$ (3 2) $\quad 7 + 9$ (6 3) $\quad 7 + 6 \quad 7 + 2$

158 Таблицаны тутыр.

+	1	2	3	4	5	6	7	8	9
7			10		12			15	
6				10		12			15

159 Югарыдагы таблицаны файдаланып исәплә.

$12 - 6 \qquad 14 - 6 \qquad 11 - 6$

$13 - 6 \qquad 15 - 6 \qquad 10 - 6$

160 Тигезләмәне схема кулланып чиш.

$(x - 10) - 40 = 60$

161 Мәсьәләләрне чишү гамәлләрен чагыштыр. Күлмәкләр тегү өчен, тукыма сатып алганнар.

1) Ефәк a м, сатин ефәктән b м га күбрәк. Ничә метр сатин алганнар?

2) Ефәк d м, сатин 12 м алынса, барысы ничә метр тукыма алганнар?

3) k м тукымадан күлмәкләр теккәч, c м калган. Ничә метр тукыма булган?

162 Мисалларны чиш.

$$\begin{array}{r} 143 \\ +\ 656 \\ \hline \end{array} \qquad \begin{array}{r} 255 \\ -\ 162 \\ \hline \end{array} \qquad \begin{array}{r} 348 \\ +\ 163 \\ \hline \end{array}$$

163 Мисалларны чиш.

6 + 5 (4, 1)　　6 + 7 (4, 3)　　6 + 9 = 9 + 6 (1, 5)

6 + 6　　6 + 4　　6 + 8

164 Таблицаны тутыр.

m	4	6	8	7	9	5
$6 + m$						

165 Югарыдагы таблицаны файдаланып чиш.

12 − 6　　11 − 6　　14 − 6
13 − 6　　10 − 6　　15 − 6

166 Баганалап язып чиш.

343 + 268　　874 + 68　　546 − 148
168 + 533　　96 + 146　　543 − 166

167 Мәсьәләләрне чишү юлларын чагыштыр.

1) Хәлимә a төп, Сания аннан b га кимрәк төп агач утыртты. Сания ничә төп агач утыртты?

2) Хәлимә c төп агач утыртты. Сания утыртканнар белән барысы d төп агач булды. Сания ничә төп агач утырткан?

3) Хәлимә k төп, Сания t төп агач утыртты. Хәлимә ничә төпкә күбрәк утырткан?

168 * урынына тиешле =, > , < билгеләрен куй.

16 − 7 * 15 − 8　　13 − 7 * 16 − 9
14 − 6 * 15 − 7　　18 − 9 * 16 − 8

169 A һәм C нокталарын сызгыч кулланып тоташтыр. AC кисемтәсенең озынлыгын үлчә.

170 3 см лы кисемтә сыз. Аны 2 см га озынайткач килеп чыккан кисемтәнең озынлыгын тап.

171 7 см озынлыгында кисемтә сыз. Аны 2 см га кыскартканнан соң калган кисемтәне дуга белән күрсәт.

172 x ны тап.



173 Сызымга саннар яз: 13, 2, 11.

174 Таблицаны тутыр.

+	1	2	3	4	5	6	7	8	9
9	10								
8		10							
7			10						
6				10					
5					10				
4						10			
3							10		
2								10	
1									10

175 Сызым буенча тигезләмәләр төзе һәм чиш.





176 Югарыдагы сызым буенча мәсьәлә төзе һәм чиш.

177 Сызымга саннар яз, мәсьәләне чиш.
Бию түгәрәгенә 64, хор түгәрәгенә 19 га азрак бала йөри. Ике түгәрәккә барысы ничә бала йөри?



178 Бию түгәрәгенә 14, чигү түгәрәгенә 9 га күбрәк бала йөри. Ике түгәрәккә барысы ничә бала йөри?

179 * урынына цифрлар яз.

$$\begin{array}{r} 60\ast \\ -\ \ 1\ast3 \\ \hline \ast57 \end{array} \qquad \begin{array}{r} 70\ast \\ -\ \ \ast3 \\ \hline 635 \end{array}$$

180 Мисалларны чиш.

906 − 396 568 + 243

780 − 142 473 + 127

181 4 тән кечерәк саннарны яз.

182 6 дан зуррак берурынлы саннарны яз.

183 x урынына нинди түгәрәк саннар куеп була?

$x < 67$ $x < 33$ $x < 26$

184 20 дән зуррак, 50 дән кечерәк түгәрәк саннарны яз.

185 x ның тигезсезлек дөрес булырлык кыйммәтен тап.

$60 - x > 56$ $146 - x > 142$

186 Мисалларны чиш.

$452 - 95$ $750 - 249$
$605 - 139$ $700 - 196$

187 $a = 18$ булганда, аңлатмаларның кыйммәтен исәплә.

$a + 5$ $20 - a$ $142 - a$ $352 + a$
$7 + a$ $a - 9$ $998 - a$ $445 + a$

188 Исәплә.

$a + c = 10$

$(a + c) + 100$ $a + c + 90$
$(a + c) - 9$ $a + 40 + c$

189 Хәрефле аңлатмаларның кыйммәтен тап.

$c = 137$ $c - 43$ $142 + c$
$c + 253$ $286 - c$ $637 - c$
$182 + c$

190 Сызым буенча мәсьәлә төзе һәм чиш.



191 Сызымга саннар дөрес язылганмы?

192 * урынына цифрлар яз.

$$\begin{array}{r} - \begin{array}{r} *** \\ 412 \\ \hline 338 \end{array} \end{array} \qquad \begin{array}{r} - \begin{array}{r} 647 \\ *** \\ \hline 165 \end{array} \end{array} \qquad \begin{array}{r} - \begin{array}{r} 898 \\ *** \\ \hline 379 \end{array} \end{array}$$

193 Телдән исәплә. Җәяләр нәрсәне аңлата?

$48 + 17 = (48 + 2) + 15$ (17 → 2, 15) $\qquad 42 + 19 = 41 + (19 + 1)$

$35 + 47 = 32 + (3 + 47)$ (35 → 32, 3) $\qquad 68 + 35 = (68 + 2) + 33$

194 Телдән исәплә.

$64 - 39 = (64 - 34) - 5$ (39 → 34, 5) $\qquad 67 - 38 = (67 - 40) + 2$

$64 - 39 = (64 - 40) + 1 \qquad 67 - 38 = (67 - 37) - 1$

195 Мисалларны чиш.

$305 - (442 - 209) \qquad 165 + (642 - 307)$

196 Мәсьәлә төзе һәм чиш.



197 Тигезлекләр дөрес булырлык итеп, җәяләр куй.

35 – 15 + 5 = 15 35 – 15 + 5 = 25

198 Тигезләмәләрне тап һәм чиш.

$x + 22 = 33$ $70 + x < 74$
$75 + 25 = 90$ $89 - x = 20$

199 $a = 42$, $a = 89$, $a = 123$ булганда, $a - 29$ аермасының кыйммәтен исәплә.

200 Ике санның суммасы кушылучыларның берсенә тигез булган мисаллар әйт.

201 Мәсьәләнең чишелешен аңлатма белән яз. Бер капта 16 китап, икенчесендә 9 китапка күбрәк. Ике капта ничә китап бар?

202 Бер сыйныфта a укучы, икенчесендә b га күбрәк. Ике сыйныфта ничә укучы бар? Аңлатмаларның кайсысы мәсьәлә чишелешенә туры килә?

$a + b$ $a + (a - b)$ $a + (a + b)$

203 x ны тап.
Бакчада барысы a төп агач үсә. Шуларның b төбе — алма, c төбе — чия, калганнары миләш агачы. Бакчада күпме миләш агачы үсә?



204 Мисалларны чиш.

900 − 549   600 − 236
300 − 29   400 − 106

205 Тигезләмәләрне чиш.

$x + 46 = 95$ $x - 38 = 45$
$56 + x = 73$ $86 - x = 49$

206 Дөреслеген тикшер.

54 + 46 = 90   98 − 49 = 49
67 + 18 = 85   68 − 37 = 21

207 Чишелеше буенча мәсьәлә төзе.

1) 13 + 4 = 17   2) 17 + 13 = 30
Җавап: 30.

208 Чишелеш аңлатма белән бирелгән. Мәсьәлә төзе.

31 + (31 − 16) = 46
Җавап: 46.

209 Аңлатмаларның кыйммәтен чагыштыр.

19 – 8 * 78 – 68 267 – 248 * 28 – 9

21 – 7 * 146 – 133 255 – 145 * 569 – 179

210 * урынына тиешле цифрларны яз.

$$\begin{array}{r} ***\\ -\;681\\ \hline 162 \end{array} \qquad \begin{array}{r} 960\\ -\;***\\ \hline 232 \end{array}$$

211 Телдән исәплә. Исәпләү юлын аңлат.

48 – 15 – 3 58 – 24 – 4

36 – 12 – 4 67 – 31 – 6

212 Телдән исәплә. Ничек исәпләдең?

69 – (15 + 44) 72 – (28 – 16)

(48 – 23) + 15 88 – (44 + 44)

213 Мәсьәләгә сызым яса һәм төрле юллар белән чиш.

Кибеттә барысы 168 сәгать бар. Шуларның 26 сы стена сәгате, 48 е өстәл сәгате, калганнары кул сәгате. Кибеттә ничә кул сәгате бар?



214 Бакчага утыртылган кыяр, помидор һәм борыч үсентеләре турында мәсьәлә төзе һәм чиш.



215 Мәсьәлә төзе.



216 Гамәлләрне башкар.

640 − 286　　805 − 462
348 + 162　　900 − 106

217 Исәплә.

27 + 8　　(27 + 8) + 27　　27 + (27 − 8)
24 − 15　　(24 − 15) + 24　　24 + (24 + 15)

218 x ның тигезсезлек дөрес булырлык кыйммәтләрен тап.

$99 - x > 95$　　$x - 95 < 3$

219 Бирелгән схема буенча ике сыйныф укучыларының саны турында мәсьәләләр төзе.



220 Ике киштәдәге китаплар саны турында мәсьәләләр төзе.



221 Схема буенча мәсьәлә төзе.



222 * урынына тиешле цифрлар яз.

$$\begin{array}{r} ***\\ -\ 381\\ \hline 219 \end{array} \qquad \begin{array}{r} 960\\ -\ ***\\ \hline 287 \end{array}$$

223 Иң кечкенә берурынлы, икеурынлы һәм өчурынлы саннарны яз.

224 Иң зур берурынлы, икеурынлы һәм өчурынлы саннарны яз.

225 Иң зур өчурынлы санга 1 не куш. Ничә урынлы сан килеп чыкты?

226 Иң кечкенә дүртурынлы сан «мең» дип укыла. Саннарны укы: 1245, 1035, 1003, 1200, 1340.

227 Гамәлләрне башкар.

900 + 100	999 + 1	839 + 161
990 + 10	647 + 353	905 + 95

228 Гамәлләрне башкар.

520 + 90	810 + 90	998 − 359
647 − 40	357 − 7	867 − 709

229 Иң кечкенә һәм иң зур дүртурынлы саннарны яз.

230 Гамәлләрне башкар.

500 + 500	300 + 700	806 − 66
900 − 400	960 − 50	580 − 70

231 Мәсьәләнең чишелешен аңлатма белән яз. Бер төргәктә 22 м, икенчесендә 9 м га күбрәк тукыма бар. Ике төргәктә барысы ничә метр тукыма бар?

а) 

ә) 

Мәсьәләгә кайсы сызым туры килә?

232 Сызым буенча мәсьәләләр төзеп чиш.

233 Гамәлләрне башкар.

(635 – 49) + 148 345 + (538 – 89)

234 $*$ урынына тиешле цифрлар яз.

$$\begin{array}{r} 5{*}7 \\ -\;\;32{*} \\ \hline {*}84 \end{array} \qquad \begin{array}{r} 8{*}0 \\ -\;\;7{*} \\ \hline {*}28 \end{array}$$

235 Берәмлекләр саны дистәләр санынннан 2 гә кечерәк булган барлык икеурынлы саннарны яз. Ничә сан яздың?

236 Тигезләмәләрне чиш.

$x + 33 = 44$ $x - 40 = 25$

$66 - x = 22$ $60 - x = 40$

237 Мәсьәләне чиш.

Бер вазадан икенчесенә 6 алманы күчергәч, ике вазада да 14 әр алма булды. Башта һәр вазада ничә алма булган?



238 Беренче өемдә 49 дәфтәр бар. Икенчесендә 20 дәфтәргә күбрәк. Өченче өемдә беренче өемдәгедән 20 дәфтәргә кимрәк. Өч өемдә барысы ничә дәфтәр бар?

239 Мәсьәлә төзе һәм чиш.



240 Гамәлләрне башкар.

$555 - 166$ $\quad$ $905 - 446$

$934 - 187$ $\quad$ $810 - 348$

241 Исәплә.

$840 + 160$ $\quad$ $648 + 362$

$805 + 195$ $\quad$ $561 + 439$

242 $a - b = 145$ булса, $258 + (a - b)$ ны тап.

243 Бер өемнән икенче өемгә 22 дәфтәр күчереп салгач, һәр өемдә 96 шар дәфтәр булган. Башта һәр өемдә ничә дәфтәр булган?



244 Сызым буенча өч киштәдәге китаплар саны турында мәсьәлә төзе һәм чиш.



245 Тигезләмәләрне чиш.

$(x - 9) + 5 = 145$ $\qquad$ $614 - (x + 8) = 485$

246 Гамәлләрне башкар.

156 – (143 – 105) $\qquad$ (205 – 109) + 203

247 Исәплә.

$$\begin{array}{r} 138 \\ +\,348 \\ \hline \end{array} \qquad \begin{array}{r} 279 \\ +\,552 \\ \hline \end{array} \qquad \begin{array}{r} 279 \\ -\,168 \\ \hline \end{array} \qquad \begin{array}{r} 505 \\ -\,362 \\ \hline \end{array}$$

248 Бер сыйныфта 23 укучы бар. Икенчесендә 4 укучыга күбрәк. Ике сыйныфта барысы ничә укучы бар?

249 Әгәр $x = 68$ булса, $139 + x$, $452 - x$ аңлатмаларының кыйммәтен тап.

250 Ике санның суммасы кушылучыларның берсенә тигез булган мисаллар яз.

251 Берәмлекләр саны дистәләр санынннан 3 кә зуррак булган икеурынлы саннарны яз.

252 Тигезләмәләрне чиш.

$(x - 20) + 82 = 169$

$67 - (x + 11) = 43$

3 КУШУ ҺӘМ АЛУНЫҢ ҮЗЛЕКЛӘРЕ.

Кисемтә ике хәреф белән билгеләнә: AB кисемтәсе.

253 AB кисемтәсенең озынлыгын үлчә.

254 AB кисемтәсен һәркайсы 1 см лы 4 тигез өлешкә бүлеп булса, аның озынлыгы 4 см га тигез була. $AB = 4$ см. Озынлыгы 6 см га тигез булган CD кисемтәсен сыз.

255 Озынлыклары 7 см, 7 см 4 мм, 8 см 5 мм булган кисемтәләр сыз. Аларны хәрефләр белән билгелә.

256 Озынлыгы 9 см га тигез булган кисемтә сыз. Аннан 2 см га озынрак булган кисемтә сыз.

257 $AB = 60$ см,
$AC = 30$ см,
$CD = 25$ см булса,
DB ны тап.

258 Сызым буенча мәсьәлә төзе.



259 *AOB*, *COD* почмакларын күрсәт. Яссылыкта бер уртак нокталары булган ике туры үткәр. Яссылык дүрт почмакка бүленер.



O ноктасы — почмакның түбәсе.
OA, *OB*, *OD*, *OC* ярымтурылары — почмакларның яклары.
Почмаклар болай билгеләнә: $\angle AOB$, $\angle BOC$, $\angle COD$, $\angle AOD$.

260 Почмакларны укы.



261



$\angle AOB = \angle BOC = \angle COD = \angle DOA$ булса, һәр почмак туры почмак дип атала.

262 Туры почмакны тап.



263 Бер туры яссылыкны ничә өлешкә бүлә?

264 Мәсьәлә төзе һәм чиш.



$a = 27$

265 Дүртпочмак якларының озынлыгын үлчә.



Кисемтәләр	AB	BC	CD	AD
Озынлыгы				

Барлык якларның озынлыклары суммасын тап.

Якларының озынлыклары суммасын дүртпочмакның периметры дип атыйлар.

266 Турыпочмаклыкның периметры күпмегә тигез?



267 Квадратның периметрын тап.



268 Өчпочмакның периметрын тап.



269 Ягы 1 дм (10 см) булган квадрат сыз. Аның периметры ничә дециметр?

270 Турыпочмаклык сыз. Аның капма-каршы якларын күрсәт.

271 Турыпочмаклыкның ничә ягы, ничә почмагы, ничә түбәсе бар? Сызып күрсәт.

272 Турыпочмаклыкның капма-каршы якларының суммасы 8 см һәм 6 см. Бу турыпочмаклыкны сыз.

273 Ягы 4 см булган квадрат сыз. Периметрын исәплә.

274 Периметры 12 см га тигез булган квадрат сыз.

275 Якларының озынлыклары 4 см һәм 3 см булган турыпочмаклык сыз. Барлык якларның озынлыклары суммасын тап.

276 Квадратның барлык яклары озынлыклары суммасы 20 см. Бу квадратны сыз.

277 Турыпочмаклыкның ике зур ягының озынлыклары суммасы 10 см. Кечкенә ягы 3 см. Периметрын исәплә.

278 Периметры 10 см га тигез булган турыпочмаклык сыз. Аның яклары сантиметрлар белән үлчәнсен.

279 Турыпочмаклыкның яклары 7 см һәм 3 см. Бу турыпочмаклыктан ягы 3 см булган ничә квадрат кисеп алып була?

280 Якларының озынлыгы 3 см булган ике квадрат бар. Аларны, берсе өстенә икенчесен ябыштырып, турыпочмаклык ясаганнар. Ябыштыру киңлеге 1 см. Турыпочмаклык якларының озынлыгын тап.

281 Турыпочмаклыкның периметры 12 см. Яклар сантиметрларда күрсәтелгән. Алар нинди озынлыкта булырга мөмкин?

Мәйданнарны чагыштыру.

282 *F* һәм *E* мәйданнарын башта *K*, аннан *M* үлчәмен кулланып чагыштыр.



283

M квадратының якларын үлчә.

Квадратның ягы 1 см булса, мәйданы 1 квадрат сантиметр (1 см^2) була.



1 см^2

284 Фигураларның мәйданын квадрат сантиметрларда (см^2) исәплә.



285 Мәйданы 8 см^2 булган турыпочмаклык сыз. Якларының озынлыгын тап. Ничә турыпочмаклык сыздың?

286 Квадратның ягы 3 см. Мәйданы ничә квадрат сантиметр? Сызым сыз.

287 Яклары 3 см һәм 4 см булган турыпочмаклык сыз. Мәйданын исәплә.

Мәйдан үлчәү берәмлекләре.

288 Ягы 1 см булган квадратның мәйданы 1 см^2. Ягы 2 см булган квадратның мәйданын тап.

289 Ягы 1 дм га тигез булган квадратның мәйданы 1 $дм^2$ (1 квадрат дециметр). Бу квадратның мәйданы ничә квадрат сантиметр? Сызымда күрсәт.

290 Ягы 1 м булган квадрат бирелгән. Аны 1 $дм^2$ лы ничә кисәккә бүлеп була?

291 Ягы 1 м булган квадратның мәйданы 1 $м^2$ (1 квадрат метр). Аның мәйданы ничә квадрат дециметр?

292 Исәплә.

2 $м^2$ = ☐ $дм^2$ 2 $м^2$ = ☐ $см^2$

300 $см^2$ = ☐ $дм^2$ 400 $дм^2$ = ☐ $м^2$

293 Бишпочмак бирелгән. Бер кисемтә үткәреп, бишпочмактан ике дүртпочмак яса.



Кушуның урын алыштыру үзлеге.

294 Телдән исәплә.

42 + 68 44 + 256 58 + 342

23 + 77 133 + 87 35 + 465

295 Сумманы тап. Нинди нәтиҗә ясадың?

243 + 257	605 + 395	468 + 331
257 + 343	395 + 605	331 + 468

296 Кисемтәләрнең озынлыгын үлчә. $AB + CD$ һәм $CD + AB$ суммаларын исәплә.

297 Уңайлы юл белән исәплә.

43 + 164	31 + 659	48 + 352
75 + 847	759 + 31	33 + 757

298 Мәсьәлә төзе һәм чиш.



299 Югарыдагы мәсьәләнең бер шартын үзгәртеп, мәсьәлә төзе һәм чиш.

Кушылучыларның урыннарын алыштырудан сумма үзгәрми.

Оештыру үзлеге.

300 Телдән исәплә.

27 + 39 + 23   68 + 49 + 12
46 + 13 + 54   55 + 67 + 15

301 *D* ны табуның төрле юлларын яз.



302 Оештыру һәм урын алыштыру үзлеген кулланып, мисалларны чиш.

423 + 20 + 77   341 + 26 + 74
245 + 36 + 755   233 + 143 + 257

303 Телдән исәплә.

42 + 68   44 + 256   642 + 88
27 + 73   133 + 87   795 + 45

304 Мәсьәлә төзе һәм чиш.



305 Исәплә.

(286 + 42) + (14 + 58)
42 + 43 + 44 + 45 + 56 + 55 + 58 + 57

Оештыру үзлеге

$$(a+b)+c=a+(b+c)$$

Саннан сумманы алу.

306 Телдән исәплә.

$76-(8+26)$ $54-(15+14)$
$(76-26)-8$ $(54-14)-15$
$67-(27+20)$ $85-(15+35)$
$(67-27)-20$ $(85-15)-35$

Нинди нәтиҗә ясап була?

307



$d-(a+b)$ һәм $d-a-b$ аңлатмаларын чагыштыр. Нинди нәтиҗә ясадың?

308 Уңайлы юл белән исәплә.

$268-132-136$ $473-(273+180)$

309 Мәсьәләне төрле ысуллар белән чиш.
Тартмада 150 алма булган. Аннан башта 53, соңыннан 67 алма алганнар. Тартмада ничә алма калган?

310 Икмәк ташучы машинада 800 икмәк булган. Бер кибеткә 250, икенчесенә 300 икмәк бушатылган. Машинада ничә икмәк калган?

311 Исәплә.

657 − (547 + 38)

845 − 123 − 222

843 − (143 + 200)

726 − (420 + 106)

Саннан сумманы алу өчен, башта бер кушылучыны, аннан соң килеп чыккан саннан икенче кушылучыны алып була.

4 ТАПКЫРЛАУ ҺӘМ БҮЛҮ ГАМӘЛЛӘРЕ.

312 m мәйданлы фигураны 3 тигез өлешкә бүл. Бер өлешнең зурлыгын күрсәт.



313 k мәйданлы фигура 5 тигез өлешкә бүленгән. Бер өлешнең мәйданы m бирелгән. Мәйданы k га тигез булган фигура сыз.



314 6 м ефәк тасманы ике кызга тигез итеп бүлгәч, һәрберсенә ничәшәр метр тасма тия?
Санлы турыга карап чиш һәм схемага ? билгесе урынына саннар яз.



315 12 дәфтәрне дүрт укучыга тигез итеп бүлгәннәр. Һәр укучыга ничәшәр дәфтәр тигән?
Схемада һәм санлы турыда күрсәт.

$\frac{b}{4} = a$ $\quad b : 4 = a$

b — бүленүче зурлык (бүленүче)
4 — өлешләр саны (бүлүче)
a — өлеш зурлык (өлеш)

316 Чагыштыр.

$\frac{b}{2} * \frac{b}{3}$ $\qquad \frac{b}{4} * \frac{b}{3}$

317 Бер үк күләмдәге сөтне Әлфия бертөрле 3, Ләйлә 4 банкага тутырып куйган. Кемнең банкаларының күләме зуррак? Алар башкарган эшне кисемтәләрдә бүлеп күрсәт.



318 Саннарны 3 тигез, 4 тигез өлешкә бүл дип әйтәсе урынга, 3 кә бүл, 4 кә бүл дип әйтәләр. Мисалларны үрнәк буенча яз: 10 : 2.

10 ны 2 гә бүл. 5 не 5 кә бүл.
4 не 2 гә бүл. 8 не 4 кә бүл.

319 Санлы туры кулланып, бүлү гамәлен башкар.

6 : 2   6 : 3   6 : 6

320 Чагыштыр.

12 : 2 * 12 : 3   М : 3 * М : 5
12 : 4 * 12 : 2   М : 5 * Н : 6

$\frac{c}{a} = b$ $c : a = b$

c — бүленүче
a — бүлүче
b — өлеш

321 Бүленүче — 8, өлеш — 4. Бүлүчене тап. Санлы туры куллан.

Өлеш зурлык һәм өлешләр саны буенча бөтен зурлыкны табу.

322 Өлеш зурлык — a.
Өлешләр саны — 4.
Бөтен зурлыкны төзе.

323 Өлеш зурлык — k.
Өлешләр саны — 5.
Бөтен зурлыкны төзе.



324 Сызымга карап, бөтен зурлыкны табарга кирәк булган мәсьәлә төзе һәм чиш.



325 Санлы туры ярдәмендә чиш.
6 баланың һәрберсенә 2 шәр йомырка пешерергә кирәк. Барысы ничә йомырка пешерергә кирәк?

$$b = a + a + a + a + a = a \cdot 5$$

$$b = a \cdot 5$$

$$b \quad = \quad a \quad \cdot \quad 5$$

бөтен зурлык — өлеш зурлык — өлешләр саны

326 $x : 5 = 2$ аңлатмасына туры килерлек итеп, машиналар турында мәсьәлә төзе.

Саннарны тапкырлау.

327 Китапханәдән 4 балага 3 әр китап бирделәр. Балаларга барысы ничә китап бирделәр?
Санлы турыда күрсәт. Схемага саннарны яз.



328 2×5 аңлатмасына сызым сыз.

c, a, b — саннар.

$$c = a \cdot b$$

c — тапкырчыгыш; a — беренче тапкырлаучы; b — икенче тапкырлаучы; $a \cdot b$ — тапкырчыгыш

329 Таблицаны кулланып, мисаллар яз.

Беренче тапкырлаучы	3	7	10	26
Икенче тапкырлаучы	4	8	5	3
Тапкырчыгыш	12	56	50	78

330 Аңлатмаларны укырга өйрән.

$3 \times 4 = 12$, яки $3 \cdot 4 = 12$.

Өчәрләп дүрт тапкыр алсаң, унике була, яки өчне дүрткә тапкырласаң, унике була.

331 Мисалларны чиш.

$\begin{array}{r}+\,257\\257\\\hline\end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r}+\,98\\98\\\hline\end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r}+\,276\\276\\\hline\end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r}+\,1945\\1945\\\hline\end{array}$

2 гә бүлү.

332 Санлы турыда 2 гә бүленә торган берничә сан билгелә.



333 1 дән 20 гә кадәр саннарны үсүче рәткә яз. 2 гә бүленә торган саннарны түгәрәк эченә ал.

334 2, 4, 6, 8, 10, 12, 14, 16, ...

Бу — җөп саннар. Рәтне дәвам ит.

335 Санлы туры ярдәмендә башкар.

$6 : 2 \qquad 14 : 2 \qquad 10 : 2 \qquad 8 : 2$

336 Санлы турыда җавапны күрсәт.



$5 \cdot 2$

$4 \cdot 2$

$3 \cdot 2$

$9 \cdot 2$

337 Сызымнарга карап, мәсьәләләр төзе һәм чиш.



2 гә тапкырлау.

338 Санлы туры кулланып, таблицаны тутыр.

a	2	3	4	5	6	7	8	9
$a \cdot 2$								

339 Югарыдагы таблицаны файдаланып, мисалларны чиш.

$3 \cdot 2$ $7 \cdot 2$ $6 \cdot 2$

$5 \cdot 2$ $2 \cdot 2$ $9 \cdot 2$

340 Мисалларны чиш.

$14 : 2$ $16 : 2$ $12 : 2$
$18 : 2$ $4 : 2$ $6 : 2$

341 Исәплә.

$28 \cdot 2$ $48 \cdot 2$ $345 \cdot 2$
$467 \cdot 2$ $289 \cdot 2$ $149 \cdot 2$

342 Аңлатмага туры килгән мәсьәлә төзе.
а) 8 не 2 тапкыр алырга.
ә) 12 не 2 гә бүләргә.

343 Схема буенча мәсьәлә төзе һәм чиш.

Санны 1 гә тапкырлау һәм бүлү.

344 Санлы турыны файдаланып исәплә.

$4 \cdot 1$ $6 \cdot 1$ $6 : 1$ $m : 1$
$5 \cdot 1$ $2 \cdot 1$ $8 : 1$ $k : 1$

$$a \cdot 1 = a$$

Теләсә нинди санны 1 гә тапкырлаганда, тапкырчыгышта шул ук сан килеп чыга.

345 Мисалларны чиш.

$32 + 19$ $\quad$ $156 : 1$

$445 - 156$ $\quad$ $321 - 49$

$242 \cdot 1$ $\quad$ $345 : 1$

346 Бүлүче 1, өлеш 6. Бүленүчене тап.

347 Бүленүче 8, бүлүче 1. Өлешне тап.

348 Мәсьәлә төзе һәм чиш.



Тапкырлауның урын алыштыру үзлеге.

349 m мәйданын башта c үлчәмен, аннары d үлчәмен кулланып исәпләгәннәр.



$m = c \cdot 5$ яки $m = 3 \cdot 5$

$m = d \cdot 3$ яки $m = 5 \cdot 3$

$3 \cdot 5 = 5 \cdot 3$ тигезлеге дөресме?

350 Калькулятор ярдәмендә тигезлекләрнең дөреслеген тикшер.

$25 \cdot 11 = 11 \cdot 25$ $48 \cdot 5 = 5 \cdot 48$

351 m санын ике юл белән тигез өлешләргә бүлгәннәр.





Урын алыштыру үзлеге

$$a \cdot b = b \cdot a.$$

Тапкырлаучыларның урыннарын алыштырудан тапкырчыгыш үзгәрми.

352 Тапкырлауның урын алыштыру үзлеген кулланып чиш.

$2 \cdot 7$ $2 \cdot 4$ $2 \cdot 8$ $1 \cdot 7$
$1 \cdot 5$ $2 \cdot 6$ $2 \cdot 9$ $1 \cdot 3$

353 Таблицаны тутыр.

a	7	4	8	1	9	2	6	5	3
$a \cdot 2$									

354 Таблицаны ятла.

a	1	2	3	4	5	6	7	8	9	10
$a \cdot 2$	2	4	6	8	10	12	14	16	18	20

Тапкырчыгышны исәпләү.

355 2 гә тапкырлау таблицасын кулланып чиш.

$2 \cdot 4$ $\quad 2 \cdot 1$ $\quad 2 \cdot 2$

$2 \cdot 6$ $\quad 2 \cdot 3$ $\quad 2 \cdot 7$

$2 \cdot 8$ $\quad 2 \cdot 5$ $\quad 2 \cdot 9$

356 Схема буенча m ны ике төрле гамәл кулланып исәпләгәннәр.



$m = a \cdot b$

$m = \underbrace{a + a + a + \ldots + a}_{b \text{ тапкыр}}$

$$a \cdot b = \underbrace{a + a + \ldots + a}_{b \text{ тапкыр}}$$

357 Мисалларны чиш.

$125 \cdot 2$ $56 \cdot 2$ $243 \cdot 2$
$421 \cdot 2$ $8 \cdot 2$ $456 \cdot 2$

358 Исәплә.

$2 \cdot 341$ $45 \cdot 2$ $2 \cdot 68$
$2 \cdot 53$ $2 \cdot 423$ $72 \cdot 2$

359 Сумманы сан белән алыштыр.

$2 + 2 + 2 + 2 + 2$ $2 + 2 + 2 + 2 + 2 + 5$
$2 + 2 + 2 + 2$ $7 + 2 + 2 + 2 + 2$
$2 + 2 + 2$ $1 + 2 + 2 + 2 + 2$

360 Мәсьәлә төзе һәм чиш.



Бүлү һәм тапкырлау гамәлләренең компонентлары арасындагы бәйләнеш.

$\frac{m}{b} = a$ $m = a \cdot b$

m — бүленүче m — тапкырчыгыш
b — бүлүче b — тапкырлаучы
a — өлеш a — тапкырлаучы

Әгәр бүлүчене өлешкә тапкырласаң, бүленүче килеп чыга.

$\frac{m}{a} = b$ яки $m : a = b$

Әгәр тапкырчыгышны беренче тапкырлаучыга бүлсәң, икенче тапкырлаучы килеп чыга.

Әгәр бүленүчене өлешкә бүлсәң, бүлүче килеп чыга.

361 $20 : 2 = 10$ тигезлегеннән өч тигезләмә төзегәннәр. x ны тап.

$x : 2 = 10$ $20 : x = 10$ $20 : 2 = x$

362 $16 : 8 = 2$ тигезлегеннән өч тигезләмә төзе һәм чиш.

363 Тигезләмәләрне чиш. Ялгышма!

$20 : x = 10$ $x : 2 = 10$
$20 - x = 5$ $x : 10 = 2$
$x - 20 = 5$ $x + 20 = 5$

364 m һәм k урынына, тигезлек дөрес булырлык итеп, саннар яз.
Ялгышма!

$m + k = k + m$ $m \cdot k = k \cdot m$
$m - k = k - m$ $m \cdot k = m + k$

365 Схема буенча аңлатма төзе.



5 кә бүлү һәм тапкырлау.

366 Санлы турыда ? билгесе урынына саннар яз.



367 25 тән 50 гә кадәрге 5 кә бүленә торган саннарны үсүче рәткә тезеп яз.

368 50 дән 90 га кадәрге 5 кә бүленә торган саннарны үсүче рәткә тезеп яз.

369 Таблицаны тутыр.

Бүленүче	10	25	30	35	20	40	5	15
Бүлүче	5	5			5		5	
Өлеш			6	7		8		3

370 Таблицаны тутыр һәм ятла!

Тапкырлаучы	5	5	5	5	5	5	5	5	5	5
Тапкырлаучы	1	2	3	4	5	6	7	8	9	10
Тапкырчыгыш										

371 Мәсьәлә төзеп чиш.



10 га бүлү һәм тапкырлау.

372 Санлы турыда ? билгесе урынына саннар яз.

373 Мисалларны чиш.

$30 + 10$	$10 \cdot 3 + 10$	$10 \cdot 4$
$40 + 10$	$10 \cdot 4 + 10$	$10 \cdot 5$
$50 + 10$	$10 \cdot 5 + 10$	$10 \cdot 6$

374 Җавапны тап.

$10 \cdot 2$	$10 \cdot 3$	$10 \cdot 4$
$10 \cdot 1$	$6 \cdot 10$	$10 \cdot 7$
$10 \cdot 5$	$7 \cdot 10$	$9 \cdot 10$

Җаваплар нинди цифр белән тәмамлана? Ни өчен?

Әгәр сан 0 цифрына тәмамланса, ул сан 10 га бүленә дигән сүз.

375 10 га бүленә торган нинди саннарны x урынына куеп була?

$x < 78$ $x < 35$ $x < 18$

376 Мәсьәлә төзеп чиш.



0 гә тапкырлау.

$m : a = 0$ булса, $m = 0 \cdot a = 0$.

$$0 : a = 0$$
$$0 \cdot a = a \cdot 0 = 0$$

Әгәр $8 : 0 = n$ булса, $8 = n \cdot 0 = 0$, $8 = 0$ була.

Нульгә бүләргә ярамый!

377 Мисалларны чиш. Ялгышма!

$2 \cdot 7$	$0 : 165$	$247 \cdot 0$
$238 \cdot 2$	$48 : 0$	$0 \cdot 141$

378 Саннарны схемага яз.

$168 : x = 42$



